СОВЕТ НИЖНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.37 А, с. Нижняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422164

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБӘН УШМЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Советлар урамы, 37А йорт, Түбән Ушмы авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422164

тел.(факс): (85563) 2-34-46; e-mail: Noshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар
05 июнь 2018 ел — № 2-31

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы № 25-ФЗ Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 14 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-6номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушмы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3.6 пунктның 12 абзацында " 2018 елның 1 гыйнвары "сүзләрен" 2020 елның 1 октябре "сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 23 статьяга түбәндәге эчтәлекле 23.15 пунктына өстәргә:

"23.15. Муниципаль хезмәткәргә ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге түләтүне куллану турында белешмәләр җирле үзидарә органы тарафыннан, «коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 15 статьясында каралган ышаныч югалтуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәр Муниципаль хезмәт узган, эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә».

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Түбән Ушмы авыл җирлеге башлыгы Р.М. Ганиевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы

Түбән Ушмы авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе /Р.М.Ганиев/